КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 апрель г.Казань № 356

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 март, 218 нче, 2020 ел, 27 март, 223 нче, 2020 ел, 30 март, 234 нче, 2020 ел, 31 март, 240 нчы, 2020 ел, 03 апрель, 252 нче, 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 10 апрель, 272 нче, 2020 ел, 13 апрель, 280 нче, 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы, 2020 ел, 21 апрель, 313 нче, 2020 ел, 29 апрель, 349 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча чараларның гамәлдә булуын озайту турында» 2020 елның 28 апрелендәге 294 номерлы Указы» сүзләрен өстәргә»;

5 пунктка «, Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча чараларның гамәлдә булуын озайту турында» 2020 елның 28 апрелендәге 294 номерлы Указының 4 пункты» сүзләрен өстәргә;

11 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта “Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы

авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2020 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указының 4 пункты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү буенча чараларның гамәлдә булуын озайту турында» 2020 елның 28 апрелендәге 294 номерлы Указының 3 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, хезмәт хакын саклап калып, эшләми торган көннәрне билгеләү турында Россия Федерациясе Президенты указының Татарстан Республикасында гамәлдә булуы кагылмый торган оешмалар исемлеге».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарын тормышка ашыру буенча чаралар хакында» үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел, 31 нче март, 240 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 06 апрель, 260 нчы, 2020 ел, 13 апрель, 279 нчы, 2020 ел, 18 апрель, 306 нчы, 2020 ел, 29 апрель, 349 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда хәрәкәт итүгә махсус рөхсәтнамәләр бирү тәртибенә, 5 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4) зиратка бару;».

3. Әлеге карар, 2020 елның 6 маеннан үз көченә керә торган 1 пунктның дүртенче абзацыннан һәм 2 пункттан тыш, 2020 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин